РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 108** **15 июнь 2015 ел**

# Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль милке капиталь төзелеше объектларына капиталь кертемнәрне гамәлгә ашыру һәм муниципаль милеккә күчемсез мөлкәт объектлары сатып алу өчен җирле бюджеттан субсидияләр бирү турында карар кабул итү тәртибен раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.2 статьясы нигезендә, **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль милке капиталь төзелеше объектларына капиталь кертемнәрне гамәлгә ашыру һәм муниципаль милеккә күчемсез мөлкәт объектлары сатып алу өчен җирле бюджеттан субсидияләр бирү турында карар кабул итү тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрләрдә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы бюджет һәм финанс департаментына йөкләргә.

А.Ф.Гәрәев

Түбән Кама шәһәре башкарма
комитеты җитәкчесенең
2015 елның 15 июнендәге
108 номерлы карары белән расланган
кушымта

**Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль милке капиталь төзелеше объектларына капиталь кертемнәрне гамәлгә ашыру һәм муниципаль милеккә күчемсез мөлкәт объектлары сатып алу өчен җирле бюджеттан субсидияләр бирү турында карар кабул итү тәртибе**

**1.Төп нигезләмәләр**

1.1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль бюджет учреждениеләренә һәм Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль автоном учреждениеләренә (алга таба - учреждениеләр), Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль унитар предпреятияләренә (алга таба – предпреятияләр), Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль милкенең капиталь төзелеш объектларын төзүгә (реконструкцияләүгә, шул исәптән реставрацияләүгә, техник җиһазлауга) капиталь кертемнәрне муниципаль учреждениеләр һәм предприятиеләр тарафыннан гамәлгә ашыруга һәм Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль милкенә күчемсез милек объектлары сатып алу өчен җирле бюджеттан субсидияләр рәвешендә бюджет ассигнованиеләре бирү турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен билгели (алга таба - карар, капиталь төзелеш объектлары, күчемсез мөлкәт объектлары, субсидия).

1.2. Карар проектын әзерләүнең инициаторы булып, җирле үзидарә органының функциональ (тармак) бүлекчәсе, Түбән Кама шәһәре муниципаль учреждениеләре һәм предприятиеләре (алга таба - тармак органы, инициатор) тора ала.

1.3. Әгәр капиталь төзелеш объектына яисә күчемсез мөлкәт объектына карата бюджет инвестицияләре әзерләү һәм аны гамәлгә ашыру турындагы карар кабул ителгән булса, җирле бюджетны үтәгәндә субсиядияләр бирү рөхсәт ителми.

Алар буенча Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль милке капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләре әзерләү һәм тормышка ашыру турында карар кабул ителгән капиталь төзелеш объектлары яки күчемсез мөлкәт объектларына карата карарлар кабул итү соңгысы үз көчен югалткан дип танылган очракта, яисә аңа бюджет акчаларын бирү формасы (бюджет инвестицияләреннән субсидияләргә) үзгәртү белән бәйле үзгәрешләр кертү юлы белән гамәлгә ашырыла.

1.4. Капиталь төзелеш объектларын яисә күчемсез мөлкәт объектларын билгеләү, Түбән Кама муниципаль районы һәм Түбән Кама шәһәренең социаль-икътисади үсеш фаразларыннан һәм программаларыннан, Түбән Кама муниципаль районы һәм Түбән Кама шәһәренең муниципаль программаларыннан, урта һәм озак сроклы чорларга үсеш стратегиясеннән, шулай ук Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегенең территориаль планлаштыру документларыннан чыгып, Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегенең үсеш өстенлекләрен һәм максатларын исәпкә алып башкарыла

1.5.Учреждениегә һәм предприятиегә бирелә торган субсидия түбәндәге эшләрне финанс белән тәэмин итүгә җибәрелми:

1.5.1. Капиталь төзелеш объектларына проект документларын эшләү яки аның турында мәгълүмат типлаштырылган проект документлары реестрына (торак һәм административ биналарга, социаль - мәдәни һәм көнкүреш билгеләнешендәге объектларга карата) кертелгән типлаштырылган проект документларын файдалануга хокук алу һәм мондый проект документларын әзерләү өчен башкарыла торган инженерлык эзләнүләре уздыру.

1.5.2. Проект документларына һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы үткәрү.

1.5.3. Капиталь төзелеш объектларының смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерү уздыру, субсидия кулланып гамәлгә ашыру планлаштырыла торган төзелешне финанс белән тәэмин итү (реконструкцияләү, шул исәптән реставрация элементлары белән дә, техник яктан яңадан җиһазлау).

1.6. Учреждениегә һәм предприятиегә бирелә торган субсидия, әгәр Түбән Кама шәһәр башкарма комитеты карары белән башкасы каралмаган булса, әлеге тәртипнең 1.5 пунктында күрсәтелгән эшләрне финанс белән тәэмин итүгә җибәрелми

## 2. Карар проектын әзерләү

2.1. Инициатор карар проектын Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты карары проекты рәвешендә әзерли. Муниципаль программа (ярдәмче программа, ведомство максатчан программасы, аерым чара) кысаларында субсидия бирелгән очракта, инициатор карар проектын тиешле муниципаль программага (ярдәмче программа, ведомство максатчан программасына) кертә һәм әгәр ул берьюлы аның координаторы булмаган очракта, аны муниципаль программа координаторы белән килештерә.

2.2. Карар проекты белән төзелеш (реконструкция, шул исәптән реставрация элементлары белән, техник яктан яңадан җиһазлау) яисә сатып алу субсидия рәвешендә каралган берничә капиталь төзелеш объекты яки бер учреждение яки предприятиенең күчемсез милек объектлары, шул исәптән Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль программасы кысаларында каралырга мөмкин.

2.3. Карар проекты түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

2.3.1. Проект документациясе нигезендә капиталь төзелеш объектының исеме (яисә карар проектын әзерләү датасына Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланган проект документлары булмаган очракта, капиталь төзелеш объектының фаразланган исеме), яисә күчемсез мөлкәт объектының исеме.

2.3.2. Юнәлеш (бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру максаты): күчемсез милек объектлары төзелеше, реконструкцияләү, шул исәптән реставрация элементлары белән дә, техник яктан яңадан җиһазлау яки сатып алу.

2.3.3. Төзүче, заказчы исеме.

2.3.4. Файдалануга тапшырылырга тиешле капиталь төзелеш объектының егәрлеге, күчемсез мөлкәт объектының егәрлеге.

2.3.5. Капиталь төзелеш объектын файдалануга тапшыру яисә күчемсез мөлкәт объектын сатып алу срогы.

2.3.6. Капиталь төзелеш объектының смета бәясе (расланган проект документлары булганда) яки капиталь төзелеш объектының фаразланган (чик) бәясе,

яисә проект документларын әзерләүгә субсидияләр күләме бүлеп бирү белән күчемсез мөлкәт объектын сатып алуның күздә тотылган (чик) бәясе һәм инженерлык эзләнүләрен үткәрүгә яисә типлаштырылган проект документларын куллануга хокук алу.

2.3.7. Проект документларын әзерләүгә һәм инженер эзләнүләрен үткәрүгә яки типлаштырылган проект документларын куллануга хокуклар алуга субсидияләр күләмен күрсәтеп, капиталь төзелеш объектларына капиталь кертемнәрне гамәлгә ашыруга юнәлдерелә торган субсидиянең гомуми (чик) күләме, капиталь төзелеш объектын сатып алуга субсидиянең гомуми (чик) күләме.

Карар проектында капиталь төзелеш объектлары турындагы мәгълүмат әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә күрсәтелергә тиеш, ә субсидия кулланып сатып алына торган күчемсез мөлкәт объектлары турындагы мәгълүмат әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә күрсәтелергә тиеш.

2.4. Карар проектын әзерләү инициаторы аны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының икътисади фаразлау, транспорт һәм элемтә бүлеге, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм архитектура идарәсе, Түбән Кама муниципаль районының бюджет һәм финанс департаменты, җирле үзидарә органнарының тиешле вазыйфаи затлары белән килештерә.

Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре»
муниципаль берәмлегенең муниципаль милке капиталь
төзелеше объектларына капиталь кертемнәрне гамәлгә
ашыру һәм муниципаль милеккә күчемсез мөлкәт
объектлары сатып алу өчен җирле бюджеттан субсидияләр
бирү турында карар кабул итү тәртибенә
1 нче кушымта

## Капиталь төзелеш объекты турында мәгълүмат формасы

(проект документлары нигезендә капиталь төзелеш объектының исеме яисә карар проекты әзерләү датасына Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланган проект документлары булмаган очракта, фаразланган исеме)

| Объект буенча төп техник-икътисади күрсәткечләр | | |
|---|---|---|
| 1 | Юнәлеш (бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру максаты): төзелеш, реконструкция, шул исәптән реставрация элементлары белән, техник яктан яңадан җиһазлау | |
| 2 | Төзүче, заказчы исеме | |
| 3 | Файдалануга тапшырылырга тиешле капиталь төзелеш объекты егәрлеге (егәрлек артуы) | |
| 4 | Капиталь төзелеш объектын файдалануга тапшыру срогы | |

| Финанс белән тәэмин итү күләме | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Күрсәткеч | Финанслау чыганагы, сум | Тормышка ашыру чоры | | | | |
| | | барлыгы | узган чор | агымдагы ел | план чорының беренче елы | һ.б |
| Капиталь төзелеш объектының смета бәясе (расланган проект документлары булганда) яки капиталь төзелеш объектының фаразланган (чик) бәясе | барлыгы | | | | | |
| | республика бюджеты | | | | | |
| | җирле бюджет | | | | | |
| | башка чыганаклар | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| шул исәптән: | | | | | | |
| проект документациясен әзерләү һәм инженерлык эзләнүләрен үткәрү яисә типик проект документларын куллану хокукларын сатып алу | барлыгы | | | | | |
| | респуб-лика бюджеты | | | | | |
| | җирле бюджет | | | | | |
| | башка чыганак-лар | | | | | |
| капиталь төзелеш объектларына капиталь кертемнәрне гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән гомуми (чик) субсидия күләме | барлыгы | | | | | |
| | респуб-лика бюджеты | | | | | |
| | җирле бюджет | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | |
| проект документациясен әзерләү һәм инженерлык эзләнүләрен үткәрү яисә типик проект документларын куллануга хокук алу | барлыгы | | | | | |
| | респуб-лика бюджеты | | | | | |
| | җирле бюджет | | | | | |
| Капиталь төзелеш объектларына капиталь кертемнәрне тормышка ашыруга юнәлдерелгән предприятиеләр яисә учреждениеләр акчаларының гомуми күләме | барлыгы | | | | | |
| | респуб-лика бюджеты | | | | | |
| | җирле бюджет | | | | | |
| | башка чыганак-лар | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | |
| проект документациясен әзерләү һәм инженерлык эзләнүләрен үткәрү яисә типик проект документларын куллануга хокук алу | барлыгы | | | | | |
| | респуб-лика бюджеты | | | | | |
| | җирле бюджет | | | | | |
| | башка чыганак-лар | | | | | |

Искәрмә: «Узган чор» графасында финанс белән тәэмин итү күләме елларга бүленмичә бер суммада чагыла.

| | |
|---|---|
| Функциональ (тармак) бүлеге җитәкчесе | _______________/__________________<br>(имза) (имзаны расшифровкалау) |

**Субсидия кулланып сатып алына торган күчемсез милек объекты турында мәгълүмат формасы**

____________________________________________________________

күчемсез милек объекты исеме

| Объект буенча төп техник-икътисади күрсәткечләр | | |
|---|---|---|
| 1 | Субсидия алучының исеме | |
| 2 | Күчемсез мөлкәт объекты егәрлеге | |
| 3 | Күчемсез мөлкәт объектын сатып алу срогы | |

| Финанс белән тәэмин итү күләме | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Күрсәткеч | Финанслау чыганагы, сум | Тормышка ашыру чоры | | | | |
| | | барлыгы | узган чор | агымдагы ел | планлы чорның беренче елы | һ.б |
| Күчемсез милек объектын сатып алуның фаразланган (чик) бәясе | барлыгы | | | | | |
| | республика бюджеты | | | | | |
| | җирле бюджет | | | | | |
| | башка чыганаклар | | | | | |
| Күчемсез милек объектын сатып алуга юнәлдерелгән субсидиянең гомуми (чик) күләме | барлыгы | | | | | |
| | | | | | | |
| | республика бюджеты | | | | | |
| | җирле бюджет | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга юнәлдерелгән учреждениеләр яисә предприятиеләрнең гомуми акча күләме | барлыгы | | | | | |
| | респуб-лика бюджеты | | | | | |
| | җирле бюджет | | | | | |
| | башка чыганак-лар | | | | | |

Искәрмә: «Узган чор» графасында финанс белән тәэмин итү күләме елларга бүленмичә бер суммада чагыла.

Функциональ (тармак) бүлеге җитәкчесе

________________/____________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)